Әти белән әнинең туган көнгә безгә рус телендә китап бүләк итә торган бик матур гадәтләре бар иде. Әти аларга бик матур итеп теләкләр яза иде. Ул китапларны без хәзер дә кадерләп саклыйбыз. Рус теленең матурлыгын күрү, аңа мәхәббәт шул вакыттан килә, күрәмсең. Үзләре дә рус телендә оста сөйләшәләр. 80 яшенә җитеп килгән әниебез Казан врачларына үз авыруы турында сөйләгәч, башта көлеп җибәргәннәр, аннары соклануларын да яшереп тормаганнар. Барлык кагыйдәләрен саклап, род- падежларын бутамыйча сөйләшә иде. Ижёвка больницасы врач- медсестралары күбесе рус милләтеннән, исән чагында телефоннан шалтыратып та, кунакка да килеп, хәл белешәләр иде. Ык Тамагыннан килеп йөрүче дядя Васяны без үзебезнең туган дип белә идек. Өй ишеген ачып кергән кешегә өйдә ипи- тоз, якты йөз була, чәй эчмичә киткән кешене белмим мин.

Җырчыларның авылдан авылга йөреп концерт куя, кунып кала торган чор иде. Кечкенә булсам да, Илһам абый Шакировның бездә кунганын хәтерлим. Сеңелем белән икебезне ике кулына алып, аңа “Гүзәлия” җырын, ә миңа “Алия- Гөлия, Гөлия тирәккәем, яшә гөлләр арасында, шул сиңа теләккәем”, дип җырлаганын онытып буламы соң. Хәмдүнә апа Тимергалиеваның әбине куркытканын да язый инде. Әби каз куып кайткан, ә караватта Хәмдүнә апа “кычкырып” ята. Әби “нәрсә булды, ник кычкырасың” дип йөгереп кергән. Җырчы апа распевка ясый икән. Әни ничек җитешкәндер, олы кунакларын бәлеш пешереп каршы ала, пич коймагы пешереп озатып кала иде.

Әти бер генә бала үскәнгә, балаларым бер- берсенә иптәш булырлар, дип, 5 бала алып кайтканнар. Безне укытырга, аякка бастырырга бик җиңел булмагандыр. Күп итеп умарта корты тотулары да шуңа булгандыр. Умарта асрау- җиңел эш түгел. Бал аертканда рамнарын ташып була да, корт аерганда аны курыкмыйча ничек җыясың, ди. Әни өйдә булмаса, курку белмәс кечкенә сеңелем Вәсилә җыя иде аларны. Бал алганнан соң, иң элек әни күчтәнәч итеп Пүләңкәдә (авылның аерылып тора торган урамын шулай атыйлар) яшәүче Исрафилов Касыйм абыйга илтә. Туган- тумачага өләшә иде.



Әти белән әнинең алтын туйлары

Әти белән әни 53 ел парлы гомер иттеләр. Бик матур итеп алтын туйларын бәйрәм иттек. 2007 елның 30 октябрендә, туган көненә 2 атна кала, әтиебез китеп барды. Ничә тапкырлар ямалган ашказаны түзмәде. Мин кайтып җиткәндә операция тәгәлләнгән, миңа әти янына реанимациягә керергә рөхсәт иттеләр. Башка вакытта мин аңа “әти, түз инде” дия идем, ул да “түзәм, кызым, түзәм” дип җавап бирә иде. Бу юлы “әти, мин кайтып җиттем”, дип кенә әйтә алдым. Яшәү ресурслары беткән иде анде. Әтинең вафатын бик авыр кичердек. Барыбыз да чирләп алдык. Азатның телефонында әтинең җыры сакланган иде. Шуны тыңлыйбыз да, елыйбыз. Әти бик матур җырлый иде. Районда үткәрелгән үзешчәннәр смотрында бер дә катнашмый калмый иде. Икешәр баянист белән җырлаганда төшерелгән фотосы да исән.

Әтисез тормыш бөтенләй башка булды. Әнине кышка авылда ялгызын калдыру безне борчый иде. Бавырына операция ясатканнан соң, без аны көз алып китеп, яз җиткәч өйгә кайтарып куя торган булдык. Абый белән киленебез Халидә гел янында булдылар. Без дә айга икешәр тапкыр кайтып, мунча кертеп, хәлен белеп китә идек. Казанда, Питрәчтә вакытта без дә, оныклары да аның янына еш барып тора идек. Авылда әнинең яшьлек дуслары, аны якын итүче кешеләр күп. Әни исән чакта, без аның белән туган- тумачаны барлап, шәҗәрә эшләргә өлгердек. Намазга әле басмасак та, догалар өйрәнә башладык. Без ураза тотканга бик тә сөенә иде, мәрхүмкәем. 2018 елның 5 февралендә, коточкыч буран көнне, әниебез дә безне калдырып китте. Кызым Алсу беркөнне әйтеп куйды: “Әби исән чакта керпегә охшаган иде, үлгәч тә онытмасыннар дигән кебек, шундый көнне китеп барды” ди. Чынлап та куркыныч көн булды ул. Мин әнинең баш очында, ике сеңлем аяк очында утырып, белгәннәребезне укып, соңгы минутына кадәр янында булдык. Кызым 4 яшьлек кызы белән такси яллап та, Вәсилә апасының өенә кадәр килеп җитә алмады, күтәреп килде. Ике машинада өч кызы,улы,бер кияүе (Фәрит алдан кайтып китте,юллар ачасы да бар бит әле) көч- хәл белән Турайга кайтып җиттек. Казанда җыелган оныклары аптырашып, без әбине озатырга кайтмыйбызмыни инде, дип, моңаеп калдылар. Без аларның

тормышын да куркыныч астына куярга теләмәдек. Аллага тапшырып кына юлга чыктык. Әни искиткеч кеше иде безнең. Авылыбызның имамы Флүрне бик ярата, хөрмәт итә иде. Аңа хат язып калдырды. Мин бер кайткач "Кызым, бу хатны Флүргә бирерсең", диде. Хатында да безне уйлаган бит ул. Балалар үзләре генә кала, мине озатканда булышырсың, дип язган. Әби- бабайларның борынгыдан килгән йолалары буенча, әнинең 3,7,40, елына, быел 2 елына Корьән ашлары уздырдык. Әниебез әйтеп калдырган васыятьләрне үтәргә тырышып яшибез. Туган нигезне, бер- берегезне ташламагыз, ди торган иде. Кирәк вакытта кайтабыз, җыелышып хуҗалыктагы эшләрне бергәләшеп эшлибез. Узган ел кайтып эти- әнинең,әбиләрнең, бабайның, Нәҗия апаның каберләрен рәтләдек. Матур чәчәкләр утырттык. Нәҗия апа гомеренең соңгы елларын Турайда эти белән әни тәрбиясендә үткәрде. Фәлимә апа белән Мөхәммәтнур абый гына Нагорный бистәсе зыяратында яталар. Азат белән Вәсилә әнине Фәлимә апаның каберенә дә алып бардылар. Ул инде бик эчтә калган, ялгыз гына керергә куркыта. Улыбыз Вадим да Мөхәммәтнур абый каберенә барып йөри. Алар безне күрәләрдер, сөенеп яталардыр дип үзара сөйләшәбез. Әти күп еллар дневник алып барган иде. Хәзер шуларны әкренләп укыйбыз. Китаплар арасыннан килеп чыккан кәгазь кисәкләре дә безнең өчен тарих. Әтинең безгә язган ике хатын, военный билетын саклыйм. Мөселман календарьлары арасыннан әни язган дога чыкты. Берсен язган да, барыбызга да өләшергә дип 4 экземпляр ксерокопия ясаткан. "Ислам дине йолалары" дигән китапны да барыбызга да алган. "Хәтер китабы"н да бишебезгә дә әзерләп куйганнар. Алар безнең күңел байлыгы турында бездән алда кайгыртып куйганнар.

Тиздән Бөек Җиңүнең 75 елын билгеләп үтәргә җыенабыз. Минем өчен ул иң авыр бәйрәм. Әти исән вакытта да, бәйрәм белән котлап шалтыраткач, эти "нинди бәйрәм инде ул, кызым, әйдә бабаңнарны искә алыйк", ди торган иде. Ул көнне мин тышта берәр эш табарга тырышам. Сугыш турында кино да карый, җыр да тыңлый алмыйм. Күз алдына әни, аның туганнары, әтинең тормыш юлы килеп баса да, ул каһәр төшкән сугыш булмаса, аларның язмышы башкача булыр иде, дигән уй йөрәкне өтәли. Безнең ике бабайга да "Хәбәрсез югалган" дигән язу килгән. Әти күп еллар аларны эзләп карады, тик бернинди дә хәбәр булмады. Интернетта "Память народа" сайты булгач кына беркадәр мәгълүмат күренә башлады. Безнең Кукмара районы Зур Сәрдек авылына "Снежный десант", КФУның музей җитәкчесе Черепанов килде. Харис "Бер хәбәр булмас микән,- дип бабайларның исемнәрен язып алып барды. Хәким бабайның 1942 елның 27 февралендә һәлак булуы, Смоленск өлкәсе Велиж районы Будница авылында җирләнгәне билгеле булды. Урынын Аллахы Тәгалә оҗмахның түреннән итсен. Ә безнең әле алар каршында үтисе соңгы бурычыбыз: Хәким бабайның каберенә зыярат кыласыбыз бар.

Әти белән әни бик матур яшәделәр. Төрле вакытлары булгандыр инде, тик минем алар кебек бер- берсен яраткан кешеләрне кинода гына күргәнем бар. Кешеләргә

күрсәткән яхшылыклары, рыясыз, киң күңелле булганнары өчен Аллахы Тәгаләнең бүләге булгандыр ул мәхәббәт. Бик тә бәхетле булдылар алар. Әти онықчыкларын күрә алмаса да, 8 оныгын күреп бәхетле иде. Әни 9 оныгы, 7 онықчыгына куанып яшәде. 4 онықчыгы карт әбиләрен шактый вакыт юксынып йөрделәр, әле дә онытмыйлар, нинди генә фотосүрәттә күрмәсеннәр- таныйлар.

Кадерле әтиебез белән әниебез турында язмамны төгәлләп киләм. Мин аны бик озак яздым. Әни сөйли иде, ул йокларга яткач, мин яза идем. Я өйдә кеше югында яздым, минем күз яшьләре белән язып утырганны беркем дә күрмәсен, дидем. Балалар, оныклар әби- бабаларын онытмасыннар, каберләренә эзне суытмасыннар, алар кебек батыр, туган җанлы булып үссеннәр, авырлыкларны җиңеп яшәргә өйрәнсеннәр дип яздым. Без барыбыз да әти- әниебезгә сокланып, алар белән горурланып, сагынып- юксынып яшибез. Үзебезгә дә аларныкы кебек матур гомер юлы үтәргә Аллахы Тәгалә насыйп итсен.



Әти белән әни кече сеңелем Вәсилә белән

Истәлик очи
тугәннәрә
саклагыз безнең
сурәтим
төнһәдә
лопонов т.
1953 ел 8
августа
8еиро-



Уңда Нажия апа, уртада әни иптәш кызлары белән



Әни тулай торакта





Фәлимә апабыз



Артта әти, аның янында әнинең туганнан туган сеңлесе Кәүсәрия апа, бу апаны белмим, Наҗия апа, Мөхәммәтнур абый, хатыны Фәүзия апа, кызлары Айсылу, сеңлебез Вәсилә белән әни



Әти дусты Зәйнак абый белән, уртадагы абыйны белмим



Әти район конкурсында җырлый



Минегаяз һәм Азат Мухаметгареевлар



Әни туганнан туган сеңлесе Тәскирә апа белән



Абый, Халидә, Тәскирә апа, әни, Тәскирә апанын кызы Әлфия ире Саша белән Турайда кунакта



Әти белән әни оныклары Вадим белән



Безнең күрше Рафис абыйны армиягә озаталар. Уң якта сумка белән Фатих абый, аның артында безнең әби. Нәкъ уртада күрше Гаян апа, аңа арты белән Ахмеров абый. Сул якта кырыйда Зөлфәт. Зэлэйхэ апа, Ясави абый баянда, ана каршы Салимгараев Рафаэль, Рафис абый узе



Безнең яңа өй. Ул йортны салу- үзе бер тарих. Мең газап белән күтәрелгән йорт ул.



Менә шундый матур кешеләр иде безнең кадерлеләребез.



Кайда төшкәннәрен дә белмим, тик алар шат, бәхетле.



Әти белән әни ял йортында. Парлап барган вакытлары шушы бер тапкыр булды бугай инде. Күпләр кызыгырлык пар бит алар.



Абый армиягә китәр алдыннан төшкән фото. Әти, энебез Азат, абыебыз Минегаяз



Әни, әти, Вәсиләнең ире Альберт, Рифкат жизни



Әти армиядә танкист, механик- водитель булган. Артта уртада



Кыек авызлы безнең яраткан әтиебез



Фәлимә апа, икенче буын кыз туганы Зәкия апа, Фәүзия апа, Мөхәммәтнур абый, икенче буын кыз туганы Кәүсәрия апа, абый, мин, Нажия апа. Без Казанда кунакта.



Турай сабантуенда. Әни белән Вадим, Гүзәлия, Вәсилә, әти, аның артында Харис, мин,

Фәрит белән Чулпан, Азат, Сания апа, Ильяс



Әни, әти, туганнан туган сеңлесе Хәлимә апа белән